СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за "Мамадышский",
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Тынычлык ур., 11А нче йорт, "Мамадыш" совхозы поселогы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

"27" декабря 2023 г. | №3-30

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең 2020 елның 17 ноябрендәге «Җир салымы турында» 5-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең 2020 елның 17 ноябрендәге «Җир салымы турында» 5-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче пунктның 1 нче пунктчасында 3 нче абзацта слова "һәм объектлар белән" сүзләрен "һәм (яисә) объектлар белән" сүзләренә, " объектка туры килгән җир участогына хокук өлешләре " сүзләрен "күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлеше" сүзләренә, "һәм объектларга" сүзләрен "һәм (яки) объектларга" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Карарның 1.1 пункты 2024 елның 1 гыйнварынннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны районның "Нократ" ("Вятка") газетасында урнаштырырыга һәм Мамадыш муниципаль районынның mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге Карараның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В. А. Гыйззәтуллинага йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Советы рәисе / В. А. Гыйззәтуллина /